**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Норма авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**23 март 2024 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Норма авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге составына кергән Норма авылы торак пункты халык җыенының 2023 елның 18 ноябрендәге № 2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:
- юл-урам челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон капламын норматив хәлгә китерү;

2) ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:
- Норма авылы торак пункты зираты өчен җиһазлар сатып алу;

3) торак пункт территориясен төзекләндерү:
- М.Вахитов урамы буена койма сатып алып урнаштыру һәм искесен ремонтлау;
- спорт мәйданчыгы төзү һәм спорт уен җиһазлары сатып алу;
- Норма авылында агач кисү, киселгән агачларны каты көнкүреш калдыклары полигоны чүп-чар җыю урынына илтү, территорияне чистарту һәм җыештыру.».

2. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы baltasi.tatarstan.ru. Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов